| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Азевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Азево авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2018 Азево авылы № 39-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының "Физик затларның милкенә салым турында"гы карарына 12.11.2014 №39-1 үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексына, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законга 06.10.2003 №131-ФЗ тәңгәлләштереп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Азево авыл җирлеге Советының "Физик затларның милкенә салым турында"гы карарына 12.11.2014 №39-1 түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктның 3 подпунктындагы дүртенче абзацны яңа редакциядә язарга: "составына бер булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекс"

2. Әлеге карар аны рәсми рәвештә бастырганнан соң үз көченә керә һәм 2018 елның 1 январеннән барлыкка килгәннән хокук мөнәсәбәтләренә тәэсире тарала.

3. Әлеге карарны Азево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына куярга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталына pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарны тормышка ашыруга контрольне үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе В.С. Семенов